**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кармалка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кармалка авыл җирлегенең Югары Кармалка**
**торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

**28 октябрь 2024 ел** **№ 10**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең Югары Кармалка авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең Югары Кармалка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 700 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш.

2. Алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (Югары Кармалка торак пунктында юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту), ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, вак ташлы-ком катнашмасы сатып алу), тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

**- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Югары Кармалка торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, алыштыру);

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә** (су

белән тәэмин итүнең урам челтәрен һәм су җыю манараларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, Югары Кармалка торак пунктындагы артезиан скважинасы территориясенең санитар-яклау зонасын төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- **традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү** (зиратларны реконструкцияләү, карап тоту, урналар кую, агачларны кисү, коры-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, керү юлларын төзекләндерү), Югары Кармалка торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү).

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу).

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Митякин